

Туган яктан туйган юк, диләр бездә.Чыннан да шулай. Бу хис барыбызга да таныш һәм якын.
Мордовия республикасы Дубенка районынын ямьле бер жирендә туган Ломатым урнашкан. Авылыбызны бер яктан урман яклый, ә жил-давыллардан - таулар саклый. Елдан-ел кvбрәк авылыбыз торле матур vзгәрешләр кичерә: сыйфатлы юллар салына, я бvрәнәдән, я кирпечтән зур якты йортлар тозелә. Ломатнын уртасында, тирә-якка нур остәп, мәчетебез балкып тора. Яз башлары килеп житvгә, хуш исләр анкытып чәчәк аткан чия-алмагачлы бакчалар кvнелләрне нечкәртә.      Туган авылымнын ин зур горурлыгы, хәзинәсе – анын хезмәт союче, тырыш, халык очен янып яшәгән якташларым. Шуларнын берсе турында язасы да язасы килә. Яраткан укытучыларымнын берсе булган Наилә апа Исмаил кызы Хайретдинова турында язмам. 1946нчы елнын 26нчы февралендә хормәтле Исмаил абый белән Алимә апанын оченче балалары булып Наилә апа якты доньяга килә. Кечкенәдән ук ул тормышта vзенен лаеклы урынын табар дип ометләр белдерә; акыллы, тырыш, матур, башлаган эшен жиренә житкереп башкарга ойрәнеп vсә. Олы абыйларыннан бик иртә укырга-язарга ойрәнә, белемгә тартыла. Алты яшеннән vзе теләп беренче класска укырга китә. Бу заманы очен сирәк очрак була. Зур теләк белән йоргән Ломат мәктәбендә бик тырышып гел «5» билгеләренә генә укый. Бишенче класста бик тә кызыксынып немец телен ойрәнә. Кирәксенеп укый Наилә апа бу телне. Укытучы булырга хыялланган бала немец теле буенча бирелгән ой эшләрен классташларына шул вакытта ук vтәргә булыша. Хыял ул бер нәрсә, ә тормыш юлы – икенче. Шулай, 1946нчы елны, мәктәпне тәмамларга жыенганда, Наилә апанын әтисе Исмаил абый, кызганычка каршы, vлеп китә. Сәләтле укучы урта мәктәпне тәмамласа да бу елны максатына ирешә алмый, укырга керергә бармый кала. Ярдәмгә укытучылары килә - мәктәптә укытырга калырга чакыралар. Шулай Наилә Исмаил кызынын туган авылы мәктәбендә педагогик биографиясенен беренче бите ачыла, немец теле буенча белем бирә башлый. Икенче елны М.Е.Евсевьев исемендәге Мордовия педагогия институтынын чит телләр факультетына укырга керә. Тәртипле һәм тырыш студент 1970нче елны «кызыл диплом» алып туган авылы Ломат мәктәбендә дипломлы педагог буларак хезмәтен дәвам итә. Мәктәптә укучылары, коллегалары, укучыларнын ата-аналары арасында Наилә апа зур хормәт яулый; аны яраталар.
«Наилә апа безне бишенче класстан алып укыта башлады, - дип истәлекләрен янарта анын укучысы Муракаев Рафик. Классыбыз зур булганга, немец теленә ике подгруппага

бvленеп бара идек. Анын дәресләре кызыклы иде, vтеп киткәнен сизми дә кала идек, чонки заманча яна технологияләр кулланып дәрес vткәрә булган, моны без vскәч анладык. Дәресләргә проигрыватель китереп немецча жырлар, шигырьләр ойрәтә иде...»
Мәрьям Ибрагим кызы гомере буе клубта директор булып эшләде. Исенә тошерә ул: «...Наилә килv белән клубта да эшебез алга китте. Без ул вакытта мәдәният учагында пьессалар куя идек. Ул актив катнашучыларнын берсе булды; рольләрне чын артистлар кvк башкарды. Концерт программаларын vзе тозде, vзе алып та барды. Концертларны Ломатта гына тvгел, кvрше авылларга да чыгып кvрсәтә идек».
Шәхси тормышы да бик матур башланып китте. Озакламый нечкә билле, кара чәчле, ямьле кыз авылнын яхшы егетенә – Сайфетдинов Анвәргә киявгә чыты. Тормыш иптәше белән бергә мәктәптә якташларынын балаларына белем бирделәр, матур йорт та салып олгерделәр. Әмма туган авылында яшәргә, мәктәбендә озак укытырга туры килмәде Наилә апага. 1976нчы елны Нижний Тагил шәһәренә туган авылын, яраткан эшен ташлап китәргә мәжбур булды. Әмма туган Ломатын, халкын беркайчан онытмады, хәбәрләшеп, аралашып, килгәләп бvген дә тора. Ерак яна жирдә, яна коллективта янадан эш башлап жибәрә ул. Зур шәһәргә килеп житv белән Наилә апа кичке мәктәпкә эшкә урнаша. Ренат мәктәпкә киткәч, икенче балалары – Шамиль туа. Бу вакытта тормыш иптәше Анвәр укый да, эшли дә; ана да жинелдән булмый. Ә укуын тәмамлагач, Урал вагоннар заводына цех начальнигы булып эшкә урнаша. Шулай яна жирдә тормышлары матурланып китә. Наилә апа шәһәрнен 39нчы мәктәбенә немец теле укытырга кvчә. Яшь укытучынын мәктәп житәкчеләре сәләтен, булдыклылыгын тиз сизеп алалар һәм аны партоешма секретаре булып куялар. Аннары завуч буларак та эшли башлый. Унышлары коннән-кон арта анын, барган юлында тукталып торырга яратмаган Наилә апаны директор вазыйфасын vтәргә кыстыйлар. Ул УрГЭУда укып экономика һәм управление белгечлеген дә алган була инде. Бvген Россиянен 100 ин яхшы мәктәбе арасында Нижний Тагилнын 39 номерлы лицее дә бар. Шул лицейны Наилә апам Исмаил кызы Хайретдинова 20ел буена житәкли, директор вазыйфасын vти. Директор беренче чиратта зур таләпләрне vзенә куя, аннары коллективына. Тырыш хезмәтләре очен Наилә апам һәм лицее олы бvләкләргә, грамоталарга, Грантларга лаек. Президентыбыз В.В.Путин кулыннан да «Ин кыйммәтле» бvләкне ала. Бvләкләренен кайберләрен әйтеп китим: Отличник народного образования РФ,  Почетная грамота Министерства общего и профессионального образования Свердловской области , Почетная грамота Губернатора Свердловской области, Серебряный Знак Законодательного Собрания Свердловской области, Отличительный Знак губернатора Свердловской области һәм башкалар.
Агымдагы елнын 26нчы феврfalендә Наилә Исмаил кызы Хайретдинованын 70-яшьлек Юбилее vтте. Ул бvген дә мәктәп директоры буларак хезмәтен дәвам итә.
*Хөрмэтле Наилэ апа!*
Сезне олы бәйрәмегез-Юбилеегыз белән котлыйбыз! Тормышыгызда кояшлы матур коннәр кvбрәк булсын. Балаларыгыз, якыннарыгыз гел куандырып торсыннар. Сәламәтлек, бәхет, хезмәтегездә тагы да югары унышларга ирешvегезне, изге ниятләрегез тормышка ашуын телибез. Без сезнен белән горурланабыз. Бу теләкләрне Ломаттагы коллегаларыгыз, дусларыгыз, укучыларыгыз юллыйлар.

Мәзидә Муракаева